ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» апреля 2021 ел № 121

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 еллардагы ягу сезонын тәмамлау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 06 маендагы 354 номерлы карары нигезендә, биш тәүлек эчендә уртача тәүлеклек һава температурасы + 8С булып сакланганда торак-коммуналь хуҗалык, ягулык-энергетика комплексы оешмаларын һәм социаль-мәдәни көнкүреш объектларын 2021-2022 еллар ягу сезонына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020-2021 еллардагы ягулык сезонын 2021 елның 03 маеннан тәмамларга.
2. АҖ «РПО «Таткоммунэнерго» җылылык белән тәэмин итүче оешмасына гамәлдәге норматив документлар һәм инструкцияләр нигезендә җылылык бирүне туктатырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://www.agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**